КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2023 ел, 13 ноябрь | г.Казань | № 1470

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында «Казан – Шәмәрдән 16+200 км – 21+977 км» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын реконструкцияләү максатларында Россия Федерациясе Җир кодексының VII бүлегенең 49 статьясы, VII[1] бүлеге, Россия Федерациясе Граждан кодексының 279 һәм 281 статьялары, Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориаль планлаштыру схемасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең (алга таба – Главтатдортранс) Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында «Казан – Шәмәрдән 16+200 км – 21+977 км» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын реконструкцияләү максатларында торак пункт җирләре категориясеннән барлыкка килә торган 16:33:080702:944 кадастр номерлы, Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Кощаково авыл җирлеге (алга таба – алына торган җир участогы) адресы буенча урнашкан, «Полимэкс» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте милкендә булган (алга таба – җир кишәрлеге милекчесе) авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясендәге 14 507 кв.метр мәйданлы җир кишәрлегеннән төзелә торган 4 886 кв.м мәйданлы җир кишәрлеген Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлегенә алмаштыру юлы белән Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен алу турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. 16:33:080702:944 кадастр номерлы жир кишәрлегендә урнашкан 16:33:0000:5842 кадастр номерлы капиталь төзелеш объекты - “Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Званка авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен төзү” су җыю корылмасы тартып алынмый дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына түбәндәгеләрне законнар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә:

10 көн эчендә:

бу карарны үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Кощаково авыл җирлеге муниципаль хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен билгеләнгән тәртиптә әлеге карарны бастырып чыгарырга;

бу карарның күчермәләрен алына торган җир кишәрлеге милекчесенә, «Роскадастр» гавами-хокукый компаниясенең Татарстан Республикасы буенча филиалына, Татарстанның юл-транспорт идарәсенә җибәрүне;

алына торган җир кишәрлегенең һәм җир Татарстан Республикасы милкендәге кишәрлегенең базар бәясен бәяләүне билгеләгәннән соң 30 көн эчендә Главтатдортранс белән берлектә җир кишәрлекләрен алмашу шартнамәсен әзерләү һәм аны алына торган җир кишәрлеге милекчесенә җибәрүне;

җир кишәрлекләрен алмашу шартнамәсен төзү;

алына торган җир кишәрлегенә Татарстан Республикасы милке хокукын дәүләт теркәвенә алуны;

алына торган җир кишәрлеге милекчесе тарафыннан имза куелган җир кишәрлекләрен алмашу шартнамәсе законнар белән билгеләнгән вакытта тапшырылмаган очракта, судка тиешле дәгъвалар бирүне.

4. Главтатдортранс継 Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында «Казан – Шәмәрдән 16+200 км – 21+977 км» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын реконструкцияләү» объекты буенча территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне ызанлау проекты составында территорияне планлаштыру документларын раслау турында» 2019 елның 28 октябрендәге 1648 номерлы карары белән расланган территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне ызанлау проекты нигезендә 16:33:080702:944 кадастр номерлы җир кишәрлегенә һәм тартып алынган җир кишәрлегенә карата кадастр эшләрен уздыруны тәэмин итәргә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин